| | |
|---|---|
| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>***БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***<br>***БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*** | РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>***БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН***<br>***БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*** |

# КАРАР
# РЕШЕНИЕ

14 ноябрь 2018ел № 4-37

«Буа шәһәре Советының 2016елның 14 апрелендәге 3-7 номерлы «Гражданнарның Буа шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм срокларын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында.

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»2017 елның 27 ноябрендәге 355-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 02 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Буа шәһәр Советы карар кабул итте:

1. Буа шәһәр Советының 2016 елның 14 апрелендәге 3-7 номерлы карары (13.04.2018 ел, № 2-31 карар редакциясендә) белән расланган Буа шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе һәм вакыты турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1 1 бүлекне 1.4 пункты белән тулыландырырга:

«1.4 «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» 2006 елның 04 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гражданнар коррупция юнәлеше фактлары буенча мөрәҗәгатьләрне органнарга җибәрергә хокуклы.

Коррупция юнәлеше фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре коррупция һәм янап куркытып алу фактлары, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен кысу, хезмәт тәртибе таләпләрен бозу, шулай ук хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган башка гамәлләр кылу турында белешмәләрне үз эченә ала.

Мөрәҗәгатьтә әзер, кылына торган яисә камилләштерелә торган хокукка каршы эш турында белешмәләр булган очракта, шулай ук аны әзерләүче, башкаручы яисә башкарган зат турында мондый мөрәҗәгать үз компетенцияләре нигезендә хокук саклау органнарына җибәрелә.

Коррупция юнәлеше фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматының һәм конфиденциаль характердагы белешмәләрнең сакланышы өчен билгеләнгән тәртиптә шәхсән җаваплы булалар.

Коррупция юнәлеше фактлары буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе органнарның норматив хокукый актлары белән билгеләнә».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча районның рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районының Буа шәһәре башлыгы М.А. Җәббаров